- уенның нәтиҗәсе укучыларның хисси халәтенә бәйле булу;
- укучыларга яхшы таныш булган ситуацияләрне файдалану;
- үзара ярдәмләшү һәм телдән актив аралашу ихтыяҗы булдыру.

Шулай итеп, татар теле дәресләрендә нәтиҗәле, мавыктыргыч һәм кызыклы итеп оештырган уеннарны куллану укытуны активлаштырырга, укучыларны фәнне үзләштерүгә, мөстәкыйль акыл эшчәнлегенә җәлеп итәргә, сәләтен ачарга һәм белем алуга кызыксыну уятырга ярдәм итә. Дәресләрдә урынлы кулланылган уеннар һәм уен элементлары укучыларның игътибарын дәрес материалына юнәлтә, иҗади халәт булдыра, туган телгә мәхәббәт һәм кызыксыну тәрбияли.

**Әдәбият**


Махмутов, М.И., Ибрагимов, Г.И., Чошанов, М.А. Педагогические технологии развития мышления учащихся / М.И. Махмутов, Г.И. Ибрагимов, М.А. Чошанов. – Казань: ИССО РАО, 1993. – 88 с.

Нурова, Л.А. Внедрение инновационных технологий в учебный процесс (на примере обучения татарскому языку) / Л.А. Нурова // В мире научных открытий. – Красноярск, 2015. – №7.4 (67). – С. 1571-1582.

Хуснутдинов, Д.Х. Функционально-семантическое изучение лексики татарского языка / Д.Х. Хуснутдинов // В мире научных открытий. – Красноярск, 2015. – № 5.1 (65). – С. 410-416.

Хуснутдинов, Д.Х., Нурова, Л.А. Использование инновационных технологий во внеклассных мероприятиях на татарском языке / Д.Х. Хуснутдинов, Л.А. Нурова // В мире научных открытий. – Красноярск, 2015. – № 11 (71). – С. 134-139.

Исәнбәт, Н.С. Нәниләр шатлана / Н.С. Исәнбәт. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1967. – 55 б.



***Һадиева Гөлфия Камиловна***

Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан


## ТӨРКИ-ТАТАР ОНОМАСТИКАСЫНЫҢ КҮРЕНЕКЛЕ БЕЛГЕЧЕ ГАРИПОВА ФИРДӘҮС ГАРИФҖАН КЫЗЫ


*Статья посвящена жизни и научной деятельности видного ученого, тюрко-татарского ономаста, доктора филологических наук, профессора Фирдаус Гариповны Гариповой.*



**Ключевые слова:** *татарский язык, ономастика, гидронимия, топонимия.*



*The article is devoted to the life and scientific activity of the famous scientist, onomast Turkic-Tatar, Doctor of Philology, Professor Firdaus Garipovny Garipova.*



**Key words:** *Tatar language, onomastics, waternames toponymy.*


«Туган җир, туган туфрак, су һәм һава – кешене кеше итә торган кыйммәтле чынбарлык. Туган җирдәге нигезебездә һава сулап, су белән чистарынып яшибез. Алар булмаса, без ничек гомер итәр идек? Язмышыңа

тагын шуларны өйрәнү дә язылган булса, бу – Аллаһы Тәгалә тарафыннан бүләк ителгән зур бәхет. Кодрәтле зат мине Ана телебезне һәм татар мәдәниятенең аерылмас бер өлеше – җир-су атамаларын өйрәнү өлкәсенә тәгаенләгән,» − дип яза Фирдәүс апа Гарипова [Гарипова, 2003: 4].

Чыннан да, тел белеменең ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган бүлеге − ономастика – гаҗәеп кызыклы дөнья. Аның җир-су, авыл атамаларын тикшерә торган юнәлеше топонимия дип атала. Топонимия төрле һәм күпсанлы исемнәрне җыю, туплау, системага салу, аларның этимологиясен, төзелеш-ясалышын, тарихи җирлеген аңлату кебек мөһим бурычларны тормышка ашыра. Ялгызлык атамалары борынгы тарихи документлар, кабер ташлары, археологик казылмалар кебек үк тарих хәбәрчеләре. Аларда халыкның теле, төбәкнең тарихы сакланып кала. Менә шушындый кыйммәтле хәзинәләрне өйрәнгән галимәләрнең берсе Гарипова Фирдәүс Гарифҗан кызы булды.

Үзенең бөтен гомерен туган төбәк, елгалар, авыллар тарихын өйрәнүгә багышлаган татар теленең күренекле белгече, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты баш гыйльми хезмәткәре, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, төрки-татар ономастикасының күренекле белгече Фирдәүс апа Гарипова 1941 елның 7 декабрендә Татарстан Республикасының Биектау районы (элекке Дөбъяз төбәге) Кодаш авылында дөньяга килә. Халыкка зур авырлыклар алып килгән 1941 ел балаларының рухы сынмаган, киресенчә, аларны чыныктырган, максатка омтылуларын көчәйткән. Әтисеннән иртә ятим калган Фирдәүс апа да тырыш булган, белемгә омтылган. 1953 елда аның гаиләсе Казанга күченеп килә. Фирдәүс Гарипова башлангыч сыйныфны Кодашта, ә урта мәктәпне Казанда тәмамлый. 1960 елда ул Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегенә укырга керә. Аны 1965 елда уңышлы тәмамлап, Биектау районының Ямаширмә авылына укытучы булып килә. 1966 елда милли китапханәдә эшли. 1970 елда Мәскәү шәһәре Ленин исемендәге дәүләт педагогика институтының дефектология факультеты каршында оештырылган берьеллык дефектологлар хәзерләү курсында укый, аннан Казан шәһәре Киров районы мәктәбендә логопед булып эшли. 1971 елда ул Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирантурага укырга керә.

Фирдәүс Гарипова ономастиканың гидронимия (су чыганаклары атамалары) тармагын махсус фән дәрәҗәсенә күтәрде. 1976 нчы елның гыйнварында ул Гомәр Фәез улы Саттаров җитәкчелегендә «Татарстанның Казан арты гидронимиясе (Ашыт, Казанка, Мишә, Шушма елгалары бассейны материаллары нигезендә)» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Әлеге диссертациянең нигезендә халыктан язып алган материаллар ята. Галимә халык сөйләгән барлык мәгълүматларны сәфәр дәфтәренә терки бара. Җыелган материалларны архивлардагы һәм борынгы чыганаклардагы мәгълүматлар белән ныгыта. Үз гомеренең тугыз елдан артыгын ул халык

арасына экспедицияләргә йөреп үткәргән. Татарстан авылларыннан гына түгел, ә башка төбәктәге татар авылларыннан материаллар җыйган. Фирдәүс апаны авылларның тарихы, халыкның теле, тормыш-көнкүреше, йола-кануннары, авыллардагы инеш-күлләрнең халәте, риваятьләр, фольклор әсәрләре кызыксындыра. Шулай итеп, галимә киләчәктәге фәнни эшчәнлеге өчен материал туплый. Үзенең истәлекләрендә ул: «Гомеремне халык арасында экспедиция-сәфәрләрдә йөреп үткәргәнмен икән мин. Язып алган мәгълүмат-материалларым бик күп. Хәзер шуларны нигез итеп алып китап-монографияләр, мәкаләләр бастырып чыгарам, ягъни халыктан язып алып кайтканны фәнни яктан нигезләп, халыкның үзенә кайтарам,» – дип яза [Гарипова, 2003: 5].

Фирдәүс апа җыйган материаллар картотекасында 200 меңгә якын атама булу үзе күп нәрсә турында сөйли. Ул 900 гә якын авыл тарихын язып калдыра. Шушы материалларның бер өлешен эченә алган «Татарстан гидронимиясе» дигән китабы 1991 нче елда Мәскәүдә «Фән» нәшриятында басылып чыга һәм ул авторга фән докторы дигән дәрәҗә китерә.

Татар теле белгече буларак, ул ономастика, тарихи лексикология, тарихи терминология, татар теленең диалектлары үзенчәлекләрен өйрәнә, география, археология, тарих, нумизматика фәннәре белән кызыксына. Фәнни юнәлешенең бер өлкәсе булган экологиягә нисбәтле проблемаларны да күтәрә.

Галимә гомере буе үз фәненә тугры булды, аның фәнни эзләнүләре нәтиҗәсе булып, егерме биштән артык китап, сүзлекләр, студентлар өчен методик ярдәмлекләр, 500 дән артык фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләре дөнья күргән, аның җитәкчелегендә кандидатлык диссертацияләре яклаган. «Татарстан гидронимнар сүзлеге» (1984, 1991), «Борынгы болгар шәһәрләре» (1990), «Татарстан микротопонимнары сүзлеге» (1991, 1992), «Елгалар дөньясына сәяхәт» (1991), «Авылларны сөям җаным-тәнем белән» (1994), «Исемнәрдә – ил тарихы» (1994), «История в названиях» (1994), «Инешләрдән иңгән моңнар бар» (1995), «Татар гидронимиясе» (1998), «Авыллар һәм калалар тарихыннан»» (2001, 2003), «Сәфәр чыксам еракларга... » (2003) «Хәтеремнән чыкмый һич тә» (2003) һ.б. хезмәтләрендә татар халкының гореф-гадәтләре, милли йолалары, рухи дөньясы, көнкүреше хакында мәгълүматлар тупланган. Аларда ялгызлык исемнәренә тарихи, этимологик, лексик-семантик, төзелеш-ясалыш ягыннан классификация ясала, җентекле анализ бирелә һәм фәнни әйләнешкә кертелә. Сүзлекләрендә исә галимә татар теле һәм татар халкы өчен зур әһәмияткә ия булган лексик берәмлекләрне туплап, системага сала. Фирдәүс Гарипова башкарган хезмәтләр, бөртекләп җыйган мәгълүматлар тел һәм тарих белеме өчен фундаменталь әһәмияткә ия, чөнки фәнгә фактик материаллар күпкә кыйммәтрәк.

Фирдәүс Гарифҗан кызының фәнни хезмәтләренә Татарстанның, Россиянең һәм бәйсез дәүләтләрнең әйдәп баручы галимнәре югары бәя

бирделәр. Алар арасында академиклар Ә.Р. Тенишев, Т.Ж. Жанузаков, М.Г. Госманов, Ә.Г. Кәримуллин, М.З. Зәкиев, Р.А. Йосыпов, профессорлар Д.М. Насипов, Э.М. Мурзаев, О.Т. Молчанова, Х. Мәхмүтов, М. Әхмәтҗанов һ.б. бар.

Фирдәүс Гарипованың хезмәтләрен галимнәр, студентлар, укытучылар гына түгел, ә киң катлам халык яратып кабул итте.

Галимә үз хезмәтләрендә зур һәм җитди проблема – экология мәсьәләсен дә күтәрә. «Бу мәсьәлә буенча чаң сугарга вакыт», − дип яза автор. − Елгалар кибә, пычрана, балыклар бетеп бара. 1969 елларда Татарстанда ун меңнән артык күл булса, хәзер аның яртысы гына калган. Су буйларын, кизләү тирәләрен сөрү бик зур зарар китерде. Кешеләр табигатьтән аерыла башлады. 1966 елда республикабызда 4855 авыл булган, ә 1987 елның 1 гыйнварына алар 3266 гына калган. Безне алыштырачак яшь буын бу урыннарда авыл булганын җөмһүриятебезнең карталарыннан карап кына беләчәк» [Гарипова, 2001: 17].

Галимә Казан дәүләт университетында (1993), Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында (1997), Казан дәүләт педагогика университетында (1997), Кабарда-Балкар дәүләт университетында (1997-2001) докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклау советларының әгъзасы булып тора. Оппонент буларак, бәяләмәләр яза, яклау советларында чыгышлар ясый. Диссертацияләрнең уңай якларын күрә белә һәм фән юлына баскан һәр яшь галимне канатландырып киңәшләрен бирә.

Фирдәүс Гарипованың фәнни эшчәнлеге дәүләтебез тарафыннан югары бәяләнде. Аңа 1995 елда «Татарстанның атказанган фән эшлеклесе», 2003 елда «Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Эзләнүчән, тынгысыз, актив, һәрчак елмаюлы якты йөзле, үз туган халкының теленә, мәдәниятенә тугрылыклы хезмәт иткән галимәбез 2014 елда вафат булды. Төрки-татар ономастикасының күренекле вәкиле Фирдәвес апа Гарипова безнең күңелләребездә озак сакланыр.

**Әдәбият**


Әмирхан, Р. Чишмәдәй чылтыраган иҗат / Р. Әмирхан // Казан утлары. – 2000. – №9. – Б.168-175.

Гарипова, Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан / Ф.Г. Гарипова. – Казан: «Матбугат йорты» нәшр-ты, 2001. – 719 б.

Гарипова, Ф.Г. Сәфәр чыксам еракларга / Ф.Г. Гарипова. – Казан: «Матбугат йорты» нәшр-ты, 2003 – 412 б.

Гарифуллин, В. Бормалыдыр фәннең юллары / В. Гарифуллин // Татарстан. – 2001. – №12. – Б. 36-37.

Иҗат баскычлары. Фирдәүс Гарипова. Биобиблиографик күрсәткеч. – Казан: ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты», 2004. – 208 б.